ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.03.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 892**

«2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру» муниципаль программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22 сентябрендәге«2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 725 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 05 мартындагы «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 158 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру» муниципаль программасын расларга.
2. Программаның гамәлдә булуын 2026 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.
3. 2026 елның 01 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга:

-«2025 елга Зеленодольск муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру» муниципаль программасын раслау турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 24 декабрендәге 5032 номерлы карары;

- «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 24 декабрендәге 5032 номерлы карары белән расланган «2025 елга Зеленодольск муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 17 апрелендәге 1043 номерлы карары;

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең (социаль мәсьәләләр буенча) урынбасарына йөкләргә.

Башлык вазифаларын башкаручы А.В. Старостин

Татарстан Республикасы Зеленодольск
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2026 елның 16 мартындагы
892 номерлы карарына
кушымта

2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы балалары һәм яшьләренең ялын оештыру буенча
муниципаль программа

1. Программа паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның атамасы | 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Зеленодольск муниципаль районы балалары һәм яшьләренең ялын оештыру буенча муниципаль программа( адга таба-программа) |
| Муниципаль заказчы | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре бүлеге |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | -Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2025 елның 22 сентябрендәге 725 номерлы карары<br>-Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 05 мартындагы 158 номерлы карары |
| Программаның төп башкаручылары | - Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре бүлеге (алга таба – ЗМР БК Яшьләр эшләре бүлеге);<br>- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе; (алга таба – ЗМР БК Мәгариф идарәсе);<br>- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе (алга таба – ЗМР БК Мәдәният идарәсе);<br>- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге (алга таба – ЗМР БК Спорт бүлеге);<br>-«Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» ДАСУ (килешү буенча);<br>-Россия эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Зеленодольск районы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>- Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Зеленодольск, Югары Ослан, Кама Тамагы, Кайбыч районнарында (Зеленодольск территориаль бүлеге) (килешү буенча);<br>- ТР буенча РФ ГТХМ Баш идарәсе дәүләт янгын күзәтчелеге идарәсенең Зеленодольск муниципаль районы буенча дәүләт |

| | |
|---|---|
| | янгын күзәтчелеге бүлеге (килешү буенча);<br> - ТР ЗМР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге (килешү буенча);<br>- «Зеленодольск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ (килешү буенча). |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Максат-балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен тиешле шартлар тудыру, сәламәтләндерү нәтиҗәсен арттыру.<br>Бурычлар:<br>-балалар һәм яшьләрнең төрле ял итү формаларын, балалар һәм яшьләр туризмын һәм спортны үстерү.<br>- сәләтле балаларны, фән олимпиадаларында, иҗади конкурсларда җиңүчеләрне ачыклау , шулай ук аларга ярдәм итү системасын формалаштыру;<br>- ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга дәүләт ярдәме күрсәтү;<br>- балалар авыруларын профилактикалау;<br>- авыр тормыш хәлендә калган балалар җәмгыяте белән нәтиҗәле комплекслы социаль яклау һәм интеграция формалаштыру;<br>- балигъ булмаганнарның караучысыз калуын һәм хокук бозуларын профилактикалау;<br>-балаларны һәм яшьләрне каникуллар чорында ял белән тәэмин итү;<br>-имин булмаган балаларның тормыш эшчәнлеген яхшырту һәм проблемаларын хәл итү;<br>- балаларны һәм яшьләрне каникуллар чорында эш белән тәэмин итү. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2026 елга һәм 2027 һәм 2028 елларның план чорына |
| Программа чаралары исемлеге | -белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган лагерьларда укучылар көндезен генә була торган сменалар , хезмәт һәм ял лагерьларында 6,5 яшьтән 18 яшьне дә кертеп балалар өчен сменалар оештыру;<br>- Зеленодольск муниципаль районы территориясендә даими яисә вакытлыча яшәүче, 7 яшьтән 17 яшьне дә кертеп иҗади сәләтле балалар һәм социаль актив балалар һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен шәһәр яны ял лагерьларында профильле сменалар һәм төрле тематик юнәлештәге сменалар һәм палатка тибындагы лагерьларда сменалар оештыру, ,шулай ук Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан гражданнар гаиләләрендәге балалар өчен, шулай ук югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гаиләләре (гаилә әгъзалары) өчен профиль сменалар һәм төрле тематик юнәлештәге сменалар оештыру;<br>-профилактик исәптә торучы балалар өчен палаткалы лагерьлардагы сменалар;<br>авыр тормыш хәлендә калган 7 яшьтән 15 яшьне дә кертеп |

<table>
<tr><td></td><td>балалар өчен ял һәм сәламәтләндерү буенча шәһәр яны лагеренда сменалар оештыру.</td></tr>
<tr><td>Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td><td>
<table>
<tr><th>Финанслау чыганаклары</th><th>Программаны гамәлгә ашыру елы 2026 ел (мең сум)</th><th>План чоры<br>2027 ел (мең сум).</th><th>План чоры<br>2028 ел (мең сум)</th></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет акчалары</td><td>749 972,00</td><td>788 837,00</td><td>834 103,00</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет акчалары</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты чаралары</td><td>74 247 200,00</td><td>78 094 900,00</td><td>82 576 200,00</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Ял өчен ата-аналар түләве күләме</td><td>7 488 127,22</td><td>9 807 233,78</td><td>10 359 334,08</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>82 485 299,22</td><td>88 690 970,78</td><td>93 769 637,08</td></tr>
</table>
</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td><td>2026 елда балаларны һәм яшьләрне ял итүнең оешкан формалары белән җәлеп итү– 7 326 кеше, 2027 һәм 2028 елларның план чорына – 7 326 кеше. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен тиешле шартлар тудыру, сәламәтләндерү нәтиҗәсен арттыру.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы</td><td>Программаны эшкә кертү буенча контрольне Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.</td></tr>
</table>

## 2. Аңлатма язуы

Әлеге программа балалар һәм яшьләр ял итү өлкәсендә сыйфатлы хезмәт күрсәтүләрдән район халкының канәгатьлеген арттыруга юнәлдерелгән. Шул ук вакытта ялның сыйфатлы булуы дигәндә балаларның иҗади потенциалын үстерүне, аларның сәламәтлеген саклауны һәм ныгытуны, балаларда авыруларны профилактикалауны, аларның физик культура, спорт һәм туризм белән шөгыльләнүен, балаларда сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыруны, аларның санитар-гигиена һәм санитар-эпидемиологик таләпләрне башкарганда уңайлы мохиттә туклану һәм тормыш эшчәнлеге режимын үтәвен тәэмин итә торган чаралар җыелмасы аңлашыла.

Традиция буенча, балалар, яшүсмерләр һәм студент яшьләренең җәйге хезмәтен һәм ялын оештыру Зеленодольск муниципаль районы эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләренең берсе булып тора.

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән тыгыз элемтәдә эшләп, Зеленодольск муниципаль районы ел саен район Башкарма комитеты җитәкчесенең тиешле карары белән районда сәламәтләндерү кампаниясен үткәрү тәртибен билгели һәм планлаштыра.

Программа гамәлдә булган чорда балалар һәм яшьләрнең тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын яхшырту буенча системалы рәвештә максатчан эш алып барыла.

Уңай тенденцияләргә карамастан, хәзерге вакытта балаларның һәм яшьләрнең сәламәтлеген саклау һәм ныгыту мәсьәләләре элеккечә актуаль булып кала.

Шулай ук районда ял итүнең агымдагы һәм перспективалы торышын билгели торган актуаль проблема булып балалар җинаятьчелеге кала бирә. Ел дәвамында җинаятьчел күренешләрнең «пигы» каникулларга туры килә, бу балигъ булмаганнар өстеннән социаль контрольнең көчсезләнүе, каникул вакытында укучылар белән эшләүнең элек булган системасының таркалуы белән бәйле.

Яшьләрне эшкә урнаштыру, аларның хәзерге җәмгыятьтә социаль адаптация проблемасы да саклана.

Әлеге күренешләрне профилактикалау өчен, балаларны лагерьларга, яшүсмерләр клубларына җәлеп итү, профильле сменалар оештыру буенча ял итү оешмаларында планлы һәм максатчан эш алып барыла.

Укучыларның педагогик яктан максатка ярашлы, эмоциональ җәлеп итүчән ялын оештыру, яңа тәэсирләргә ихтыяҗны канәгатьләндерү, иҗади яктан үз-үзеңне тормышка ашыру, аралашу һәм хезмәт, белем, сәнгать, мәдәният, уен һәм үз-үзеңне билгеләү өчен мөмкин булган башка өлкәләрен үз эченә алган үзешчәнлекнең төрле формалары өчен уңай шартлар тудырырга кирәк.

3. Программаны гамәлгә ашыруның максатлары, бурычлары, чаралары, көтелгән ахыргы нәтиҗәләре тасвирламасы, аны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Программаның максаты-балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру, сәламәтләндерү нәтиҗәлелеген арттыру .

3.1. Куелган максатка ирешү түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән гамәлгә ашырыла:

3.1.1. Балалар һәм яшьләрнең төрле ял итү формаларын, балалар һәм яшьләр туризмын һәм спортны үстерү.

3.1.2. Сәләтле балаларны, фән олимпиадаларында, иҗади конкурсларда җиңүчеләрне ачыклау, аларга ярдәм итү системасын формалаштыру.

3.1.3. Ятим балаларга, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга ярдәм күрсәтү.

3.1.4. Балалар авыруларын һәм инвалидлыкны профилактикалау.

3.1.5.Балигъ булмаганнар арасында караучысызлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалау

3.1.6. Авыр тормыш хәлендә калган балаларны нәтиҗәле комплекслы социаль яклау һәм җәмгыятькә интеграцияләү формалаштыру.

3.1.7. Балаларны һәм яшьләрне каникул чорында ял белән тәэмин итү.

3.1.8. Имин булмаган балаларның тормыш-көнкүрешен яхшырту һәм проблемаларын хәл итү.

3.1.9. Балаларны һәм яшьләрне каникул вакытында эш белән тәэмин итү.

2026 нчы елда Зеленодольск муниципаль районы балалары һәм яшьләре өчен ял оештыру план Программаның 1 нче кушымтасында бирелгән.

2026 елга һәм 2027 һәм 2028 елларның план чорына максатлар, бурычлар, чаралар, гамәлгә ашыру сроклары, индикаторлары Программаның 1 нче кушымтасында бирелгән.

2026 елга муниципаль программаны гамәлгә ашыруның ахыргы нәтиҗәсе булып каникул вакытында 7 326 баланы төрле ял итү формалары белән тәэмин итү, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен тиешле шартлар тудыру, сәламәтләндерү нәтиҗәлелеген арттыру тора.

## 4. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

2026 елда Программаны финанслауның гомуми күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә
82 485 299,22 сум:
- 74 247 200,00 сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;
- 749 972,00 сум – җирле бюджет акчалары;
- 7 488 127,22 сум – ата-аналар акчалары (килешү буенча).

2027 елда Программаны финанслауның гомуми күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә
88 690 970,78 сум:
- 78 094 900,00 сум – Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;
- 788 837,00 сум – җирле бюджет акчалары;
- 9 807 233,78 сум – ата-аналар акчалары (килешү буенча).

2028 елда Программаны финанслауның гомуми күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә
93 769 637, 08 сум:
- 82 576 200,00 сум – Татарстан Республикасы бюджет акчалары;
- 834 103,00 сум – җирле бюджет акчалары;
- 10 359 334,08 сум – ата-аналар акчалары (килешү буенча).

Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр төзелгән Килешүләр нигезендә бирелә.

Программаны тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативлары, ял оештыруга хезмәтләр күләме нормативлары һәм балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруны финанслау күләмен бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2025 елның 22 сентябрендәге 754 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» 2019 елның 05 мартындагы 158 номерлы карары нигезендә кабул ителде.

## 5. Программаны гамәлгә ашыру механизмы.

Программаны гамәлгә ашыру Программаның муниципаль заказчысы тарафыннан гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә программа чараларын башкаручыларның барысы белән дә төзелә торган муниципаль ихтыяҗлар өчен продукцияне сатып алуга һәм китерүгә муниципаль контрактлар (шартнамәләр) нигезендә башкарыла.

Балалар һәм яшьләрнең ялы һәм сәламәтләндерү сменаларында катнашучылар булып түбәндәгеләр тора:

- Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы 6,5 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар;

- Зеленодольск муниципаль районы территориясендә даими яисә вакытлыча яшәүче, 7 яшьтән 17 яшьне дә кертеп, иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар, өстәмә гомуми белем бирү, гомуми үстерү һәм һөнәри әзерлек программаларын үзләштерүче укучылар, спорт әзерлеге узучы балалар;

-авыр тормыш хәлендә калган балалар: бала тууга һәм тәрбияләүгә бәйле пособие алучылар; социаль яктан куркыныч хәлдә булган гаиләдә яшәүче балалар; физик һәм (яисә) психик үсешләрендә кимчелекләре булган, үз-үзләренә хезмәт күрсәтергә сәләтле сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар; качаклар һәм мәҗбүри күчеп китүчеләр, кораллы һәм милләтара конфликтлар корбаннары гаиләләрендәге балалар, экологик һәм техноген һәлакәтләр, табигый бәла-казалар; үз-үзен девиант (иҗтимагый яктан куркыныч) тотучы, махсус тәрбия, белем шартларына мохтаҗ һәм махсус педагогик якын килүне таләп итүче, шул исәптән профилактик исәптә торучы балалар; килеп туган хәлләр нәтиҗәсендә тормыш эшчәнлеге объектив рәвештә бозылган һәм әлеге хәлләрне мөстәкыйль рәвештә яисә гаилә ярдәме белән җиңә алмаган балалар, экстремаль шартларда калган балалар; махсус хәрби операцияне уздыруда катнашучы гражданнарның гаиләләреннән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар арасыннан балалар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре, Махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның гаиләләреннән булган балалар.

Шәһәр читендәге лагерьларда муниципаль һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең балалары, коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар хезмәткәрләренең балалары өчен (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш),шәһәр читендәге ял итү лагерьларында профильле сменалар һәм төрле тематик юнәлештәге сменалар, иҗади сәләтле балалар һәм социаль актив балалар һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен палатка тибындагы лагерьларда сменаларны ТР ЗМР «Исток» ОМК» МБУ, «6 нчы спорт мәктәбе (Бригантина)» МБУ , «Зеленодольск шәһәре мәдәни үсеш үзәге» МБУ оештыралар.

Укучылар (мәктәп яны) көндез була торган белем бирү оешмалары оештырган лагерьларда һәм хезмәт һәм ял лагерьларында сменаларны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф белән идарә итү буенча ведомство буйсынуындагы учреждениеләр оештыра.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Җәй» балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерүне, ял иттерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә түбәндәгеләрне тәкъдим итә:

агымдагы елның 15 апреленә кадәр - ял итү оешмаларын ачу графикларын;

ел дәвамында лагерьга кергән көнне - оператив мәгълүмат.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәгеләрне тапшыра:

агымдагы елның 1 маена кадәр - мәгариф оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге, ял һәм хезмәт лагерьларын ачу графигын;

ел дәвамында көндә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы билгеләгән формалар буенча - оператив мәгълүматны һәм һәр айның

25 числосына ай саен- белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге, ял һәм хезмәт лагерьларында балаларның ялын һәм эшен оештыру турында йомгаклау мәгълүматын.

Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру, аларны сәламәтләндерүне, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә, шулай ук аның составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

6. Программаның социаль-икътисади, экологик, бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү.

Программаның нәтиҗәлелеге билгеләнгән срокларда чараларны үтәү дәрәҗәсе буенча бәяләнә.

Программаны гамәлгә ашырудан экологик нәтиҗәлелек үсеп килүче буынның әйләнә-тирә мохиткә сакчыл мөнәсәбәткә карата әхлакый тәрбияне берләштерүдән тора.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү Программаның координаторы тарафыннан ел саен үткәрелә.

Әлеге программаның нәтиҗәлелеген бәяләүнең төп критерийлары сыйфат һәм сан күрсәткечләреннән тора, аларны исәпләгәндә ял итү һәм сәламәтләндерү белән бәйле балаларның гомуми саны исәпкә алына.

Муниципаль программаны гамәлгә ашыруның барышы һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләү турында еллык хисап (алга таба – еллык хисап) Программа координаторы тарафыннан әзерләнә һәм хисаптан соң килүче елның 1 мартына кадәр раслау өчен ЗМР Башкарма комитетына җибәрелә.

Еллык хисап ел саен 25 апрельгә кадәр, хисаптан соң килүче елның 25 апреленә кадәр «Идарә» дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында электрон рәвештә урнаштырыла.

Еллык хисап әлеге Программаның 3 нче кушымтасында тәкъдим ителгән форма буенча тутырган мәгълүматны һәм түбәндәге бүлекләрдән торган аңлатма язманы үз эченә ала

1) хисап чорында ирешелгән конкрет нәтиҗәләрне;

2) билгеләнгән срокларда үтәлгән һәм үтәлмәгән (сәбәпләрен күрсәтеп) чаралар исемлеген;

3) Программаны гамәлгә ашыру барышына йогынты ясаган факторларны анализлауны;

4)чараларны башкаруга бюджет ассигнованиеләрен һәм башка акчаларны куллану турында мәгълүмат;

5) Программаның координаторы тарафыннан муниципаль программага кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүмат.

7. Программаны гамәлгә ашыруның төп социаль-икътисади эффекты

7.1. Балаларның һәм яшьләрнең ялы, аларны савыктыру өлкәсендә халыкның сыйфатлы хезмәт күрсәтүләре белән канәгатьлек дәрәҗәсе арту, балаларның һәм яшьләрнең авырулар дәрәҗәсе кимү.

7.2. Тормыш эшчәнлеген яхшырту һәм имин булмаган балалар проблемаларын хәл итү.

7.3. Ятим балаларны, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны ярдәм итү.

7.4. Каникул чорында балаларны һәм яшьләрне ял, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итү. Программаның бюджет нәтиҗәлелеге җәйге ялны тәэмин итү чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыруда чагыла. Программаны финанслау

чыганакларына бүлеп гамәлгә ашыру өчен кирәкле ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү.

1 нче кушымта

2026 елда Зеленодольск муниципаль районы балалары һәм яшьләренең ялын оештыру планы

Иҗади сәләтле яисә социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен палаткалы лагерьларда профильле сменалар оештыру

| Палаткалы лагерь(оештыручы) исеме | Үткәрү территориясе | Ял белән җәлеп ителгән кеше саны | Ял көннәре саны | ТР бюджетыннан субсидияләр (сум) | Ата-ана түләве (сум) | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет) (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| ТР ЗМР «6 нчы спорт мәктәбе (Бригантина)» МБУ | Россия Федерациясе | 160 | 7 | 1 822 247,38 | 560 000,00 | 18 406,54 |
| **БАРЛЫГЫ:** | **х** | **160** | **х** | **1 822 247,38** | **560 000,00** | **18 406,54** |

2026 елда гомуми белем бирү оешмалары укучыларының көндезге лагерьларында сменаларны оештыру

| Лагерьны оештыру өчен база (мәктәп) | Үткәрү территориясе | Ял белән җәлеп ителгән кеше саны | Ял көннәре саны | ТР бюджетыннан субсидияләр (сум) | Ата-аналар взносы(сум) | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет) (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Җәйге чорда | | | | | | |
| «ТР ЗМР Васильево штп Н. Соболев исемендәге 2 нче лицей» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 155 | 21 | 800 305,13 | 142 656,88 | 8 083,89 |
| ТР ЗМР С. К. Гыйматдинов исемендәге | Зеленодольск муниципаль районы | 90 | 21 | 464 693,28 | 82 833,04 | 4 693,88 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Осиново гимназиясе» МБГБУ | | | | | | |
| «В.В. Карпов исемендәге лицей» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 300 | 21 | 1 548 977,66 | 276 110,10 | 15 646,24 |
| «ТР ЗМР Раифа урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 50 | 21 | 258 162,94 | 46 018,35 | 2 607,71 |
| «ТР ЗМР Норлат урта гомуми белем мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 40 | 21 | 206 530,36 | 36 814,68 | 2 086,16 |
| «ТР ЗМР Свияжск (Зөя) урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 65 | 21 | 335 611,83 | 59 823,85 | 3 390,02 |
| «ТР ЗМР 1 нче лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 155 | 21 | 800 305,13 | 142 656,88 | 8 083,89 |
| «ТР ЗМР 3 нче гимназия» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 155 | 21 | 800 305,13 | 142 656,88 | 8 083,89 |
| «ТР ЗМР 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 130 | 21 | 671 223,65 | 119 647,71 | 6 780,04 |
| «ТР ЗМР 5 нче гимназия» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 135 | 21 | 697 039,04 | 124 249,55 | 7 040,81 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «ТР ЗМР Советлар Союзы Герое В.Х. Хаҗиев исемендәге 7 нче лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 155 | 21 | 800 305,13 | 142 656,88 | 8 083,89 |
| «ТР ЗМР А.С. Пушкин исемендәге 9 нчы лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 250 | 21 | 1 290 814,71 | 230 091,75 | 13 038,54 |
| «ТР ЗМР 10 нчы гимназия» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 155 | 21 | 800 305,13 | 142 656,88 | 8 083,89 |
| «ТР ЗМР 11 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 135 | 21 | 697 039,94 | 124 249,55 | 7 040,81 |
| «ТР ЗМР 14 нче лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 135 | 21 | 697 039,94 | 124 249,55 | 7 040,81 |
| «ТР ЗМР 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 155 | 21 | 800 305,13 | 142 656,88 | 8 083,89 |
| «ТР ЗМР 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 60 | 21 | 309 795,53 | 55 222,02 | 3 129,25 |
| «ТР ЗМР Н.А. Катин исемендәге 17 нче төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 30 | 21 | 154 897,76 | 27 611,02 | 1 564,62 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «ТР ЗМР М.В. Ломоносов исемендәге 18 нче күп профильле лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 250 | 21 | 1 290 815,62 | 230 091,75 | 13 038,53 |
| **БАРЛЫГЫ:** | **х** | **2600** | **х** | **13424473,04** | **2392 954,20** | **135 600,76** |

Җәйге чорда (хезмәт һәм ял лагере)

| Лагерьны оештыру өчен база (мәктәп) | Үткәрү территориясе | Ял белән җәлеп ителгән кеше саны | Ял көннәре саны | ТР бюджетыннан субсидияләр (сум) | Ата-аналар взносы(сум) | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет) (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «ТР ЗМР Васильево штп Н. Соболев исемендәге 2 нче лицей» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 60 | 18 | 312 398,86 | | 3 155,54 |
| «ТР ЗМР С. К. Гыйматдинов исемендәге Осиново гимназиясе» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 35 | 18 | 182 232,66 | | 1 840,73 |
| «В.В. Карпов исемендәге лицей» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 80 | 18 | 416 531,81 | | 4 207,39 |
| «ТР ЗМР Раифа урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 15 | 18 | 78 099,71 | | 788,89 |
| «ТР ЗМР | Зеленодольск | 10 | 18 | 52 066,48 | | 525,92 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Норлат урта гомуми белем мәктәбе» МБГБУ | муниципаль районы | | | | | |
| «ТР ЗМР Свияжск (Зөя) урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 20 | 18 | 104 132,95 | | 1 051,85 |
| «ТР ЗМР 1 нче лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 60 | 18 | 312 398,86 | | 3 155,56 |
| «ТР ЗМР 3 нче гимназия» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 60 | 18 | 312 398,86 | | 3 155,56 |
| «ТР ЗМР 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 30 | 18 | 156 199,43 | | 1 577,77 |
| «ТР ЗМР 5 нче гимназия» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 30 | 18 | 156 199,43 | | 1 577,77 |
| «ТР ЗМР Советлар Союзы Герое В.Х. Хаҗиев исемендәге 7 нче лицей» МБГБУ . | Зеленодольск шәһәре | 60 | 18 | 312 398,86 | | 3 155,56 |
| «ТР ЗМР А.С. Пушкин исемендәге 9 нчы лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 70 | 18 | 364 465,33 | | 3 681,47 |
| «ТР ЗМР 10 нчы гимназия» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 55 | 18 | 286 365,62 | | 2 892,58 |
| «ТР ЗМР 11 | Зеленодольск | 45 | 18 | 234 299,14 | | 2 366,66 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | шәһәре | | | | | |
| «ТР ЗМР 14 нче лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 40 | 18 | 208 265,80 | | 2 103,70 |
| «ТР ЗМР 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 60 | 18 | 312 398,86 | | 3 155,54 |
| «ТР ЗМР 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 20 | 18 | 104 132,95 | | 1 051,85 |
| «ТР ЗМР Н.А. Катин исемендәге 17 нче төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 10 | 18 | 52 066,48 | | 525,92 |
| «ТР ЗМР М.В. Ломоносов исемендәге 18 нче күп профильле лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 70 | 18 | 364 465,43 | | 3 681,42 |
| **БАРЛЫГЫ:** | **х** | **830** | **х** | **4 321 517,52** | | **43 651,68** |

Язгы чорда

| Лагерьны оештыру өчен база (мәктәп) | Үткәрү территориясе | Ял белән җәлеп ителгән кешеләр саны | Ял көннәре саны | ТР бюджетыннан субсидияләр (сум) | Ата-аналар взносы (сумнарда) | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет) (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «ТР ЗМР Әйшә гимназиясе» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 35 | 7 | 60 238,02 | 10 737,61 | 608,46 |
| «ТР ЗМР Васильево штп Н. Соболев исемендәге 2 нче лицей» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 60 | 7 | 103 265,18 | 18 407,34 | 1 034,08 |
| «ТР ЗМР Большие Ключи урта гомуми белем бирү мәктәбе»МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 30 | 7 | 51 632,59 | 9 203,67 | 521,54 |
| «В.В. Карпов исемендәге лицей» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 70 | 7 | 120 476,04 | 21 475,23 | 1 216,93 |
| «ТР ЗМР С. К. Гыйматдинов исемендәге Осиново гимназиясе» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 40 | 7 | 68 843,45 | 12 271,56 | 695,39 |
| «ТР ЗМР 1 нче лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 55 | 7 | 94 659,75 | 16 873,40 | 956,16 |
| «ТР ЗМР 3 нче гимназия» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 55 | 7 | 94 659,74 | 16 873,40 | 956,16 |
| «ТР ЗМР 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 40 | 7 | 68 843,45 | 12 271,55 | 695,39 |
| «ТР ЗМР 5 нче гимназия» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 35 | 7 | 60 238,02 | 10 737,62 | 608,46 |
| «ТР ЗМР Советлар Союзы Герое В.Х. Хаҗиев исемендәге 7 нче лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 55 | 7 | 94 659,75 | 16 873,40 | 956,16 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «ТР ЗМР А.С. Пушкин исемендәге 9 нчы лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 65 | 7 | 111 870,61 | 19 941,28 | 1 130,00 |
| «ТР ЗМР 10 нчы гимназия» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 40 | 7 | 68 843,45 | 12 271,56 | 695,39 |
| «ТР ЗМР 11 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 40 | 7 | 68 843,45 | 12 271,56 | 695,39 |
| «ТР ЗМР 14 нче лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 40 | 7 | 68 843,45 | 12 271,56 | 695,39 |
| «ТР ЗМР 15 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 55 | 7 | 94 659,75 | 16 873,40 | 956,16 |
| «ТР ЗМР 16 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 25 | 7 | 43 027,15 | 7 669,73 | 434,62 |
| «ТР ЗМР М.В. Ломоносов исемендәге 18 нче күп профильле лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 60 | 7 | 103 265,18 | 18 407,33 | 1 052,08 |
| БАРЛЫГЫ: | х | **800** | **х** | **1376869,03** | **245431,20** | **13 907,76** |

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашучы, шулай ук элегрәк катнашкан гражданнар гаиләләреннән, шулай ук югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гаиләләреннән (гаилә әгъзаларыннан) балалары өчен(җәйге чор).

| Лагерьны оештыру өчен база (мәктәп) | Үткәрү территориясе | Ял белән җәлеп | Ял көннәре саны | ТР бюджетыннан | Ата-аналар взносы | Башка чаралар (предприяти |
|---|---|---|---|---|---|---|

| | | ителгән кеше саны | | субсидияләр (сум) | (сумнарда) | еләр, җирле бюджет) (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «ЗМР ТР Василиево штп Совет Союзы Герое Н. Соболев исемендәге 2 нче лицей» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 19 | 21 | 116 583,00 | | |
| «В.В. Карпов исемендәге лицей» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 31 | 21 | 190 213,00 | | |
| «ТР ЗМР Свияжск (Зөя) урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 11 | 21 | 67 497,00 | | |
| «ТР ЗМР Советлар Союзы Герое В.Х. Хаҗиев исемендәге 7 нче лицей» МБГБУ . | Зеленодольск шәһәре | 16 | 21 | 98 176,00 | | |
| «ТР ЗМР А.С. Пушкин исемендәге 9 нчы лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 16 | 21 | 98 176,00 | | |
| «ТР ЗМР 10 нчы гимназия» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 13 | 21 | 79 769,00 | | |
| «ТР ЗМР 11 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 13 | 21 | 79 769,00 | | |
| «ТР ЗМР 14 нче лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 12 | 21 | 73 634,00 | | |
| «ТР ЗМР М.В. Ломоносов исемендәге 18 нче күп профильле лицей» МБГБУ | Зеленодольск шәһәре | 19 | 21 | 116 583,00 | | |
| БАРЛЫГЫ: | x | **150** | **x** | **920 400,00** | | |

Шәһәр яны ял лагерьларында профиль сменалар һәм төрле тематик юнәлештәге сменалар оештыру.

| Стационар балалар | Үткәрү территориясе | БСЛ балансты | Ял белән җәлеп | Ял көнн әре | ТР бюджетынн ан | Ата-ана түләве (сум) | Башка чаралар (предприят |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| сәламәт ләндерү лагере (БСЛ) исеме | | тотучының исеме | ителгән кеше саны | саны | субсидияләр (сум) | | иеләр, җирле бюджет) (сум) |
| Муниципаль йөкләмә нигезендә | | | | | | | |
| Муса Җәлил исемендәге БСУ | Зеленодольск муниципаль районы | ТР ЗМР «Исток» яшьләр клублары берләшмәсе» МБУ | 336 | 18 | 7 064 737,72 | 4 197 705,12 | 71 360,99 |
| Үткәрелгән ачык торглар нәтиҗәсендә | | | | | | | |
| **х** | Зеленодольск муниципаль районы | х | 1 084 | 18 | 22614711,70 | х | 407 664,04 |
| **х** | Зеленодольск муниципаль районы | х | 700 | 7 | 5 723 745,84 | х | 57 815,61 |
| Барлыгы: | **х** | **х** | **2 120** | **х** | **35403195,26** | **4 197 705,12** | **536 840,64** |

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә аерым хәрби операциядә катнашкан, шулай ук элек катнашкан, һәм шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) югарыда күрсәтелгән категорияләр гражданнарының балалары өчен профиль сменалары һәм төрле тематик юнәлешле сменалар оештыру (ачык торглар нәтиҗәләре буенча).

| Стационар балалар сәламәтләндерү лагере (БСЛ) исеме | Үткәрү территориясе | БСЛ балансқа тотучының исеме | Ял белән җәлеп ителгән кеше саны | Ял көннәре саны | ТР бюджетыннан субсидияләр (сум) | Ата-ана түләве (сум) | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет) (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Х** | Зеленодольск муниципаль районы | Х | 50 | 18 | 1 249 300,00 | Х | Х |
| **Барлыг** | **х** | **х** | **50** | **х** | **1 249 300,00** | Х | Х |

| ы: | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

Авыр тормыш хәлендә булган 7 яшьтән 15 яшьне дә кертеп балалар өчен шәһәр яны лагерьларында сменалар оештыру (ачык торглар нәтиҗәләре буенча).

| Стационар балалар сәламәтләндерү лагере (БСЛ) исеме | Үткәрү территориясе | БСЛ баланста тотучының исеме | Ял белән җәлеп ителгән кеше саны | Ял көннәре саны | ТР бюджетыннан субсидияләр (сум) | Ата-ана түләве (сум) | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет) (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль йөкләмә нигезендә | | | | | | | |
| Муса Җәлил исемендәге БСУ | Зеленодольск муниципаль районы | ТР ЗМР «Исток» яшьләр клублары берләшмәсе» МБУ | 84 | 7 | 859 026,84 | х | х |
| Үткәрелгән ачык торглар нәтиҗәсендә | | | | | | | |
| **х** | Россия Федерациясе | х | 462 | 21 | 14 173 873,16 | х | х |
| Барлыгы: | **х** | **х** | **546** | **х** | **15 032 900,0** | х | х |

Профилактик исәптә торган балалар өчен палаткалы лагерьларда профиль сменалар оештыру.

| Палаткалы лагерь исеме | Үткәрү территориясе | БСЛ балансta тотучының исеме | Ял белән җәлеп ителгән кеше саны | Ял көннәре саны | ТР бюджетыннан субсидияләр (сум) | Ата-аналар взносы(сум) | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет) (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ТР ЗМР «6 нчы спорт мәктәбе (Бригантина)» | Зеленодольск муниципаль районы | х | 40 | 7 | 541 400,00 | х | х |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| МБУ | | | | | | | |
| **Барлыгы:** | **x** | **x** | **40** | **x** | **541 400,00** | x | x |

Көндезге дагерьларда  укучылар сменаларын оештыру

| Лагерьны оештыру өчен база | Үткәрү территориясе | Ял белән җәлеп ителгән кеше саны | Ял көннәре саны | ТР бюджетыннан субсидияләр(сум) | Ата-аналар түләве (сум) | Башка чаралар (җирле бюджет) (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| ТР ЗМР «Зеленодольск шәһәре мәдәни үсеш үзәге» МБУ | Зеленодольск муниципаль районы | 30 | 21 | 154 897,77 | 92 036,70 | 1 564,62 |
| **БАРЛЫГЫ:** | **x** | **30** | **x** | **154 897,77** | **92 036,70** | **1 564,62** |

2 нче кушымта

2026 елга программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| Максатның атамасы | Бурычның атамасы | Ярдәмче программаның исеме | Төп - чаралар аталышы | Башкаручылар | Төп чараларның үтәү срогы | - Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, кеше | Индикаторлар күрсәткече (кеше) | | | | | | Финанслау чыганакларын күрсәтеп финанслау (сум) * | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | 2026 ел | 2026 елда көтелгән нәтиҗәләр | 2027 ел | 2027 елда көтелгән нәтиҗәләр | 2028 ел | 2028 ел көтелгән нәтиҗәләре | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| Балаларның һәм яшьл-әрнең ялын һәм сәламә | Балаларны һәм яшьләрне каникул чорында ял белән | | Укучыларның көндезге лагерьларда - | Мәгариф оешмалары | 2026 елгы җәйге каникуллар | балалар саны (квота буенча) | 2600 | 2600 | 2600 | 2600 | 2600 | 2600 | 13 424 473,04 – ТР бюджетыннан субсидия* 2 392 954,20 – ата-аналар | 14 035 094,07 – ТР бюджетыннан субсидия* 2 501 799,3 –ата-аналар | 14 675 120,46 – ТР бюджетыннан субсидия* 2 615 886,00 – ата-аналар |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| тлэнде-рүен оеш-тыру өчен тиешле шартлар тудыру, сәламәтләндерү эффектын арттыру | тәэмин итү | | сменаларын оештыру | | | | | | | | | | взносы 135 600,76 – җирле бюджеттан субсидия | взносы 141 768,63 - җирле бюджеттан субсидияләр | взносы 148 233,54 - җирле бюджеттан субсидияләр |
| | Балаларны һәм яшьләрне каникулчорында эш белән тәэмин итү | | Балаларның көндезге лагерьларда сменаларын оештыру | Мәгариф оешмалары | 2026 елгы җәйге каникуллар | балалар саны (квота буенча) | 830 | 830 | 830 | 830 | 830 | 830 | 4 321 517,52 – ТР бюджетыннан субсидия* 43 651,68 - җирле бюджеттан субсидия | 4 518 084,58 – ТР бюджетыннан субсидия* 45 637,22- җирле бюджеттан субсидия | 4 724 117,64 – ТР бюджетыннан субсидия* 47 718,36- җирле бюджеттан субсидия |
| | Балаларны һәм яшьләрне каникулчорында ял белән тәэмин итү | | балаларның көндезге лагерьларда сменаларын оештыру | Мәгариф оешмалары | Язгы кани-куллар 2026 ел | балалар саны (квота буенча) | 800 | 800 | 800 | 800 | 800 | 800 | 1 376 869,03 – ТР бюджетыннан субсидия* 245 431,20 – ата-аналар взносы 13 907,76 - җирле | 1 439 496,83– ТР бюджетыннан субсидия* 256 594,8 – ата-аналар взносы 14 540,37- җирле бюджеттан | 1 505 140,56 – ТР бюджетыннан субсидия* 268 296,00 – ата-аналар взносы 15 203,44 - җирле |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | бюджеттан субсидияләр | субсидияләр | бюджеттан субсидияләр |
| | балаларны һәм яшьләрне каникул чорында ял белән тәэмин итү; | | балаларның көндезге лагерьларда сменаларын оештыру | Мәгариф оешмалары | 2026 елгы җәйге каникуллар | балалар саны (квота буенча) | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | 920 400,00 – ТР бюджетыннан субсидия* | 962 230,5 – ТР бюджетыннан субсидия* | 1 006 110,00 – ТР бюджетыннан субсидия* |
| | сәләтле балаларны, фән олимпиадаларында, иҗади конкурсларда җиңүчеләрне ачыклау, | | Көндезге дагерьларда укучылар сменаларын оештыру | «Зеленодольск шәһәре мәдәни үсеш үзәге» МБУ | Июнь 2026 ел. | балалар саны (квота буенча) | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | 30 | 154 897,77 – ТР бюджетыннан субсидия 1 564,62 –– Җирле бюджеттан субсидияләр 92 036,70 – ата-ана | 161 943,39 – ТР бюджетыннан субвенция* 1 635,79 – җирле бюджеттан субсидия 28 866,92 – ата-аналар взносы | 169 328,31 – ТР бюджетыннан субсидия* 1,39 – җирле бюджеттан субсидия 30 183,30 – ата-ана взносы |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | аларга ярдәм итү системасын формалаштыру; балаларны һәм яшьләрне каникул чорында ял белән тәэмин итү | | | | | | | | | | | | взносы | | |
| | сәләтле балаларны, фән олимпиадаларында, иҗади конкурсларда җиңүчеләрне ачыкла | | шәһәр яны - лагерьларында профильле сменалар - оештыру | ТР ЗМР «Исток» яшьләр клублары берләшмәсе» МБУ | Җәйге, кышкы ,язгы 2026 ел көзге каникул. | балалар саны (квота буенча) | 2 120 | 2 120 | 2 120 | 2 120 | 2 120 | 2 120 | 35 403 195,26 – ТР бюджетыннан субсидия* 536 840,64 – җирле бюджеттан субсидия 4 197 705,12 – | 37 246 494,67 – ТР бюджетыннан субсидия 565 579,05 — җирле бюджеттан субсидия 6 672 750,36 – | 39 472 215,75 – ТР бюджетыннан субсидия* 600 081,07 – җирле бюджеттан субсидияләр 7 071 624,0 |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | у, аларга ярдәм итү системасын формалаштыру. | | | Мәгариф оешмалары | | | | | | | | ата-аналар взносы | ата-аналар взносы | 6 – ата-аналар взносы |
| | балалар һәм яшьләрнең төрле ял итү формаларын, балалар һәм яшьләр туризмын һәм спортны үстерү; | | пал-аткалы лаг-ерьларда профильле сменалар оештыру | ТР ЗМР «6 нчы спорт мәктәбе (Бригантина)» ӨБ МБУ | 2026 елның июнь-августы | балалар саны (квота буенча) | 160 | 160 | 160 | 160 | 160 | 160 | 1 822 247,38 – ТР бюджетыннан субсидия* 560 000, 00 – ата-аналар взносы 18 406,54 – җирле бюджеттан субсидия | 1 947 917,66 – ТР бюджетыннан субсидия* 347 222,40 – ата-аналар взносы 19 675,94 – җирле бюджеттан субсидия | 2 094 463,88 – ТР бюджетыннан субсидия* 373 344,72 – ата-аналар взносы 21 156, 20 — җирле бюджеттан субсидияләр |
| | авыр тормыш хәлендә калган балала | | Пал-аткалы лаг-ерьларда | ТР ЗМР «6 нчы спорт мәктә | 2026 елның июнь-августы | балалар саны (квот | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 | 541 400, 00 – ТР бюджетыннан субсидияләр | 578 704, 00 – ТР бюджетыннан субсидияләр | 622 241, 20 – ТР бюджетыннан субсидия* |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | р җәмгыяте белән нәтиҗәле комплекслы яклау һәм интеграция формалаштыру; балигъ булмаганнарның караучысызлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау; имин булмаган балала | | профилактик исемлеккә кертелгән балалар өчен профиль сменасы оештыру | бе (Бригантина)» ӨБ МБУ | | а буенча) | | | | | | | р* | р* | |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | рның тормыш - көнкүреш ен яхшырту һәм проблемалары н хәл итү; | | | | | | | | | | | | | | |
| | ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга дәүләт ярдәме; авыр тормыш хәлендә калган балалар җәмгыяте | | авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен шәһәряны лаг-ерьларында сменалар оештыру | ТР ЗМР «Исток» яшьләр клублары берләшмәсе » МБУ | 2026 ел | балалар саны (квота буенча) | 546 | 546 | 546 | 546 | 546 | 546 | 15 032 900, 00 – ТР бюджетыннан субсидия* | 15 890 538,30 — ТР бюджетыннан субсидия* | 16 914 496, 20 – ТР бюджетынан субсидия* |

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | белән нәтиҗәле комплекслы яклау һәм интеграция формалаштыру; балигъ булмаганнарның караучысызлыгын һәм хокук бозуларын профилактикалау; имин булмаган балаларның тормыш - | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | көнкүреш ен яхшырту һәм проблемаларын хәл итү; | | | | | | | | | | | | | |
| | балаларны һәм яшьләрне каникул чорында ял белән тәэмин итү; | | Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренең балалары өчен шәһәряны лагерьларында сменалар оештыру | ТР ЗМР «Исток» яшьләр клублары берләшмәсе» МБУ | 2026 елның гыйнвар-декабре | балалар саны (квота буенча) | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 1 249 300,00 – ТР бюджетыннан субсидия* | 1 314 396,00 – ТР бюджетыннан субсидия* | 1 392 966,00 — ТР бюджетыннан субсидия* |

*-финанслаштыру Татарстан Республикасы балалар һәм яшүсмерләр ялын оештыру буенча финанс чыгымнары нормативларына ярашлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22 сентябрендәге «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 725 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 05 мартындагы «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 158 номерлы карары белән билгеләнгән.
* ТР - Татарстан Республикасы

3 нче кушымта

| | |
|---|---|
| Муниципаль программа реквизитлары, гамәлгә ашыру чоры | |
| Муниципаль программаны раслау турында норматив хокукый актның исеме | |
| Форманы төзү өчен җаваплы вазыйфаи зат<br>(Ф. И.Ат.и., вазыйфасы, элемтә өчен телефоны) | |

2026 елда муниципаль программаны гамәлгә ашыру турында хисап

| № т/б | Программаның (ярдәмче программаларның) (бүлекнең, чаралар) исеме | Финанслау чыганагы (барлыгы, шул исәптән Россия Федерациясе бюджеты, Татарстан | Хисап елына планлаштырылган финанслау күләме, мең сум | Хисап елына муниципаль программа буенча бүлеп бирелгән (лимит), | Фактта хисап елында акчалар файдаланылган, мең сум | Индикатор исеме | Индикатор күрсәткечләре | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | узган ел | | агымдагы ел | | | киләсе елга план |
| | | | | | | | план | факт | план | факт | үтәлү проценты | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Республикасы бюджеты, җирле бюджет) | | мең сум | | | | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| Муниципаль программа буенча барлыгы | | Барлыгы | | | | | | | | | | |
| | | Россия Федерациясе бюджеты | | | | | | | | | | |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | | | | | | | | | | |
| | | җирле бюджет | | | | | | | | | | |